ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.09.2021 г. Заинск № 560

**«Төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак объектының яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында»**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2018 елның 6 мартындагы 360 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак объектының яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. “Төзелгән яисә реконструкцияләнгән индивидуаль торак объектының яисә бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 2018 елның 10 декабрендәге 1812

номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **Р.М. Архипова**

Р.Р. Исламова
3-47-87